ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Площадь Победы, 4, город Бавлы,
423930

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Җиңү мәйданы, 4, Баулы шәһәре,
423930

Тел.: (85569) 5-29-50, факс: (85569) 5-38-72. E-mail: Bavly.Gorispolkom@tatar.ru,
сайт: www.bavly.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.09.2021 Баулы шәһәре №92

Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 3 августындагы 77нче “Агачларны, куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә, агач утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 3 августындагы 77нче “Агачларны, куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә, агач утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” карары белән расланган Агачларны, куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә, агач утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2.3.1 пунктчасында «агачларның, куакларның авария хәлендә булу турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4 пунктны төшереп калдырырга;

1.4. 2.8.2 пунктынның 2 пунктчасында «яисә гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне кисү кирәклеген тикшерү нәтиҗәсендә аларны кисү кирәк булу (авария хәлендә булу) расланмаса.» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасындагы «(авария-торгызу эшләрен уздыруга бәйле очраклардан тыш (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 2.8.4 пунктта «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 3.4.2 пунктның дүртенче абзацында «, мөрәҗәгать итүче шулай ук авария-торгызу эшләрен уздыру яисә аеруча кирәкле шартларда (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт алган очракта)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 3.5.2.3 пунктны төшереп калдырырга;

1.9. 3.5.5 пунктта «мөрәҗәгать итүче авария-торгызу эшләрен башкарганда (авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) - 2 эш көне.» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.10. Регламентка 2 нче кушымтадагы «Авария хәлендәге агачлар кыска вакытта киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстем алам.

«Баулы шәһәре» муниципаль<br>берәмлеге Башкарма<br>комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров